ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.07.2022 №137пи

Балык Бистәсе штп.

2022-2023 елларга Балык Бистәсе муниципаль районы халкы арасында дәрестән тыш вакытта гомуми белем бирү оешмаларында халык тарафыннан физкультура-спорт инфраструктурасын куллану тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе президиумының «Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының халык тарафыннан физкультура-спорт инфраструктурасыннан файдалану турында» 30.09.2021 ел, № ПР-29-1 карарының 4 пунктын үтәү йөзеннән, КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

2012-2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкы арасында дәрестән тыш вакытта гомуми белем бирү оешмаларында халыкның физкультура-спорт инфраструктурасын куллану тәртибен (алга таба - тәртип);

2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкы арасында дәрестән тыш вакытта гомуми белем бирү оешмаларында физкультура-спорт инфраструктурасын халык тарафыннан куллану графигын.

2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге»муниципаль казна учреждениесен тәртипнең заказчы – координаторы итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкчесе Р. Л. Исланов

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022
елның 04 июлендщге № 137пи
карары белән расланган

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең физкультура-спорт инфраструктурасын халык тарафыннан укудан тыш вакытта куллану тәртибе.

### I.Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре (алга таба-гомуми белем бирү учреждениеләре) балансында торучы һәм муниципаль милектә булган физкультура – сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларын кулланучының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, физик тернәкләндерү һәм физкультура - сәламәтләндерү һәм спорт ялын оештыру ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында бирү мәсьәләләрен җайга сала.

### II. Билгеләмәләр

2.1. Әлеге тәртиптә тиешле билгеләмәләр булган түбәндәге терминнар кулланыла:

физкультура-сәламәтләндерү хезмәте: кулланучының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, физик тернәкләндерү, шулай ук физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт ялын үткәрү ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча эшчәнлеге.

физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмалары: биналар, корылмалар, махсус техник чаралар белән җиһазландырылган, физкультура-сәламәтләндерү, спорт хезмәтләре, спорт - тамаша чаралары, шулай ук физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт ялын оештыру өчен билгеләнгән бүлмәләр.

спорт җиһазлары: спорт һәм физкультура чараларын уздыру урыннарын җиһазлый торган приборлар, аппаратлар, җайланмалар.

Спорт кирәк-яраклары һәм инвентарьлары: кулланучыларга хезмәт күрсәтү процессын тәэмин итү өчен кирәкле әйберләр, җайланмалар комплексы.

хезмәт күрсәтүче персонал: физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-педагогик эш белән шөгыльләнүче һәм законнарда билгеләнгән спорт һәм һөнәри квалификациясенә ия булган затлар.

### Ш. Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларын бирү тәртибен классификацияләү

3.1. Спорт-тамаша чараларын үткәрү үз эченә ала:

- турнирларда, спорт ярышларында катнашучылар өчен спорт һәм сәламәтләндерү чаралары;
- спорт бәйрәмнәре;
- спорт-тамаша кичәләре һәм концертлар;

күренекле спортчылар белән очрашулар;

- әйдәп баручы спортчылар һәм спорт учреждениеләре вәкилләренең күрсәтмә чыгышлары.

3.2. Халыкка физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларын (объектларны) күрсәтү үз эченә ала:

- укыту-тренировка процессын үткәрү;

-физкультура һәм спорт чаралары үткәрү өчен физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларыннан файдалану

- сәламәтләндерү өчен объектларны куллану;

- спорт җиһазларыннан (тренажерлар, снарядлар, инвентарьлар) файдалану;

- квалификацияле хезмәт күрсәтүче персонал белән тәэмин итү, көч һәм сәламәтлекне торгызу, шулай ук актив ял итү өчен шартлар тудыру.

## IV.Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларына таләпләр

4.1 Хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган объектлар физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларына куела торган норматив таләпләргә туры килергә тиеш.

4.2. Объектларда булырга тиеш:

- оператив идарә хокукында муниципаль мөлкәт белән файдалану турында килешү;

- хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

- спорт корылмаларының техник паспорты;

- спорт корылмасы паспорты;

- спорт корылмаларының физкультура һәм спорт чарасын үткәрүгә әзерлеге акты.

- спорт корылмаларының уку елына әзерлеге акты.

4.3. Объектлар территориясен карап тоту махсус хезмәтләрнең техник чараларының (янгын, коткару, санитария һ.б. техника) ирекле йөрүен тәэмин итәргә тиеш.

4.4. Хезмәт күрсәткәндә объектлар, шулай ук алар тирәсендәге территориянең эш, кизү тору һәм авария хәлендәге яктыртылуы булырга тиеш.

4.5. Объектлар санитар-гигиеник, янгынга каршы таләпләргә, хезмәткәрләрнең, килүчеләрнең һәм физкультура һәм спорт чараларында катнашучыларның куркынычсызлыгына туры килергә тиеш.

4.6. Спорт җиһазлары, кирәк - яраклар һәм инвентарь аларга норматив документларда билгеләнгән куркынычсызлык таләпләренә туры килергә һәм җитештерүче предприятиенең эксплуатация документларында бәян ителгән кагыйдәләр нигезендә кулланылырга тиеш.

Мәҗбүри сертификатлаштырылырга тиешле спорт җиһазлары, кирәк-яраклар һәм инвентарь, билгеләнгән тәртиптә сертификатлаштырылырга тиеш , ә мәҗбүри сертификатлаштырылырга тиеш булмаганнарының җитештерүченең яраклылык һәм куркынычсызлыгын раслаучы документы булырга тиеш .

4.7. Спорт объектларында күрсәтелә торган физкультура - сәламәтләндерү һәм спорт хезмәтләре (алга таба-хезмәтләр) ГОСТ Р 52024-2003. туры килергә тиеш.

Мондый хезмәтләр күрсәтү куркыныч булган спорт объектларында хезмәт күрсәтү рөхсәт ителми.

4.8.Спорт объектлары барлык коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтү чаралары белән тәэмин ителергә тиеш.

V. физкультура һәм спорт корылмаларын бирү тәртибе

5.1. Персоналның тиешле белеме, квалификациясе, профессиональ әзерлеге, үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәре һәм тәҗрибәсе булырга тиеш. Мәҗбүри медицина тикшерүен узарга (эшкә кергәндә) һәм вакытлы медицина тикшерүләрен узарга.

5.2. Персонал даими рәвештә яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү курслары узарга тиеш. Учреждениенең һәр хезмәткәре өчен аларның вазыйфаларын һәм хокукларын билгели торган вазифа инструкциясе булырга тиеш.

5.3. Оешмаларга һәм халыкка объектлар тапшырганда, Учреждение кулланучыларны түләүсез, аңлаешлы һәм дөрес мәгълүмат белән тәэмин итәргә тиеш.

5.4. Мәҗбүри тәртиптә мәгълүмат составына кертелә:

- физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре;
- шикаять һәм тәкъдимнәр китабы;
- куркынычсыз хезмәт күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары;
- учреждение җитәкчесе тарафыннан расланган укыту-тренировка дәресләрен үткәрү методикасы һәм программасы (дәресләр расписаниесе);
- физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт хезмәтләре күрсәтүгә кертелгән персоналның квалификациясе турында мәгълүмат;
- янгын куркынычсызлыгы һәм хезмәтне саклау буенча инструкция;
- - терроризм-җәмгыятькә янау буенча мәгълүмат стенды (бинага кергәндә урнаштырыла).

5.5. Төрле дәрәҗәдәге физкультура һәм спорт чараларын уздыру, аларны оештыручыларга, төрле милек формасындагы учреждениеләр һәм оешмалар булган спорт корылмаларында (спорт җиһазларын, кирәк-яракларын, инвентарьларын куллану) оператив идарә хокукында гомуми белем бирү учреждениеләре белән язмача килешергә тиеш.

Халыкка социаль әһәмиятле хезмәтләр табыш алу чыганагы буларак каралырга тиеш түгел.

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022
елның 04 июлендщге № 137пи
карары белән расланган

2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкы арасында дәрестән тыш вакытта гомуми белем бирү оешмаларында физкультура-спорт инфраструктурасын халык тарафыннан куллану графигы

| МО исеме | Спорт залларының эш графигы | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Дүшәмбе | Сишәмбе | Чәршәмбе | Пәнҗешәмбе | Җомга | Шимбә | Якшәмбе |
| МББУ "1 нче Балык Бистәсе гимназиясе» | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 19.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| «Балык Бистәсе 1 нче гимназиясе» МББУ филиалы Олы Кульга мәктәбе | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| МББУ "2 нче Балык Бистәсе урта мәктәбе" | - | 18.00 – 20.30 | - | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| "Балыклы Чүкәй урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Биектау урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Олы Елга урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Олы Елга урта мәктәбе» МББУ филиалы Ш. Тулуш төп гомуми белем бирү мәктәбе | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Зур Мәшләк урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Югары Тегермәнлек урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Күгәрчен урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Котлы Бөкәш урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Масловка урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Яңа Арыш урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| Шомбыт урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| «Корноухово урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Куки урта мәктәбе» МББУ | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| МББУ “Түбән Тегермәнлек урта мәктәбе” гомуми белем бирү мәктәбе” | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| МББУ “Трой Урай төп гомуми белем бирү мәктәбе” | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| МББУ “Урахча төп гомуми белем бирү мәктәбе” | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| МББУ “Шомырбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе” | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| МББУ “Юлсубино төп гомуми белем бирү мәктәбе” | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 10.00-18.00 |
| МБОУ «Ямашевская ООШ» МББУ “Ямаш төп гомуми белем бирү мәктәбе” | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | 18.00 – 20.30 | - | - | 10.00-18.00 |